**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет

Бирючевского сельского

поселения Азнакаевского

муниципального района

ул. Школьная, д.2, д.Бирючевка, 423307

Тел. (88-5592) 61881, факс (8-592) 61881

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл жирлеге
башкарма комитеты

Мэктэп урамы, 2, Бирючевка авылы, 423307,Тел. (88-5592) 61881, факс (88-5592) 61881

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» сентябрь 2019 ел №83

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Бирючевка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 төркем инвалидлардан түләүне

киметеп, аны 150 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- юлларга асфальт җәю (сатып алу, ташу, асфальт салу, килешү буенча эш өчен түләү) Мира ур.,Бирючевка авылы; Молодежная ур., Бирючевка авылы;
-авыл халкына бәйрәмнәрне оештыру өчен: “Сабантуй”,”Картлар көне”,”Яна ел” бәйрәмнәре өчен;

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Бирючевка авылы, Мәктәп ур., 2 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;
- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,
- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: М.Г.Нуреева